**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» и Кодекс Республики Татарстан о муниципальной службе

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
26 декабря 2016 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 25 октября 2005 года № 106-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2003, № 1; 2005, № 10 (II часть); 2006, № 12 (I часть); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I часть), № 12 (I часть); 2009, № 12 (I часть); 2010, № 1 – 2, № 10 (II часть); 2011, № 5, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 2 (I часть), № 3, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II часть) следующие изменения:

1) часть 1 статьи $13^1$ изложить в следующей редакции:

«1. Предельный возраст пребывания на государственной службе – 65 лет. Государственному служащему, достигшему предельного возраста пребывания на государственной службе, замещающему должность государственной службы категории «помощники (советники)», учреждаемую для содействия лицу, замещающему государственную должность Республики Татарстан, срок государственной службы с согласия данного государственного служащего может быть продлен по решению представителя нанимателя до окончания срока полномочий указанного лица.»;

2) в статье 45:

а) в пункте 1 части 1 слова «не менее 15 лет» заменить словами «, продолжительность которого для назначения пенсии за выслугу лет в соответствующем году определяется согласно приложению к настоящему Закону»;

б) в части 4 слова «стажа государственной службы 15 лет» заменить словами «стажа государственной службы, продолжительность которого для назначения пенсии за выслугу лет в соответствующем году определяется согласно приложению к настоящему Закону,», слова «сверх 15 лет» заменить словами «сверх указанного стажа»;

в) абзац первый части 6 после слов «оклад за классный чин,» дополнить словами «ежемесячное денежное поощрение в размере, не превышающем месячного должностного оклада,»;

3) дополнить приложением следующего содержания:

«Приложение
к Закону Республики Татарстан
«О государственной гражданской
службе Республики Татарстан»

**Стаж государственной гражданской службы
для назначения пенсии за выслугу лет**

| Год назначения пенсии за выслугу лет | Стаж для назначения пенсии за выслугу лет в соответствующем году |
|---|---|
| 2017 | 15 лет 6 месяцев |
| 2018 | 16 лет |
| 2019 | 16 лет 6 месяцев |
| 2020 | 17 лет |
| 2021 | 17 лет 6 месяцев |
| 2022 | 18 лет |
| 2023 | 18 лет 6 месяцев |
| 2024 | 19 лет |
| 2025 | 19 лет 6 месяцев |
| 2026 и последующие годы | 20 лет». |

**Статья 2**

Внести в Кодекс Республики Татарстан о муниципальной службе (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2013, № 6 (II часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II часть) следующие изменения:

1) в статье 28:

а) в пункте 1 части 1 слова «не менее 15 лет» заменить словами «, продолжительность которого для назначения пенсии за выслугу лет в соответствующем году определяется согласно приложению 5 к настоящему Кодексу»;

б) в части 4 слова «стажа муниципальной службы 15 лет» заменить словами «стажа муниципальной службы, продолжительность которого для назначения пенсии за выслугу лет в соответствующем году определяется согласно приложению 5 к настоящему Кодексу,», слова «сверх 15 лет» заменить словами «сверх указанного стажа»;

в) часть 8 после слов «должностной оклад» дополнить словами «, ежемесячное денежное поощрение в размере, не превышающем месячного должностного оклада,»;

2) дополнить приложением 5 следующего содержания:

«Приложение 5
к Кодексу Республики Татарстан
о муниципальной службе

**Стаж муниципальной службы
для назначения пенсии за выслугу лет**

| Год назначения пенсии за выслугу лет | Стаж для назначения пенсии за выслугу лет в соответствующем году |
|---|---|
| 2017 | 15 лет 6 месяцев |
| 2018 | 16 лет |
| 2019 | 16 лет 6 месяцев |
| 2020 | 17 лет |
| 2021 | 17 лет 6 месяцев |
| 2022 | 18 лет |

| | |
|---|---|
| 2023 | 18 лет 6 месяцев |
| 2024 | 19 лет |
| 2025 | 19 лет 6 месяцев |
| 2026 и последующие годы | 20 лет». |

**Статья 3**

1. За лицами, проходившими государственную гражданскую службу Республики Татарстан, муниципальную службу в Республике Татарстан, приобретшими право на пенсию за выслугу лет в соответствии со статьями 45, 46 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан», статьей 28 Кодекса Республики Татарстан о муниципальной службе и уволенными со службы до 1 января 2017 года, лицами, продолжающими замещать на 1 января 2017 года должности государственной гражданской службы Республики Татарстан, должности муниципальной службы в Республике Татарстан и имеющими на 1 января 2017 года стаж государственной гражданской службы, стаж муниципальной службы для назначения пенсии за выслугу лет не менее 20 лет, лицами, продолжающими замещать на 1 января 2017 года должности государственной гражданской службы Республики Татарстан, должности муниципальной службы в Республике Татарстан, имеющими на этот день не менее 15 лет указанного стажа и приобретшими до 1 января 2017 года право на страховую пенсию по старости (инвалидности) в соответствии с Федеральным законом от 28 декабря 2013 года № 400-ФЗ «О страховых пенсиях», сохраняется право на пенсию за выслугу лет в соответствии со статьями 45, 46 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан», статьей 28 Кодекса Республики Татарстан о муниципальной службе без учета изменений, внесенных настоящим Законом в части 1 и 4 статьи 45 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан», части 1 и 4 статьи 28 Кодекса Республики Татарстан о муниципальной службе.

2. Лицам, замещавшим должности государственной гражданской службы Республики Татарстан, муниципальной службы в Республике Татарстан, которым пенсия за выслугу лет назначена до вступления в силу настоящего Закона, размер пенсии за выслугу лет подлежит перерасчету с 1 января 2017 года с применением положений части 6 статьи 45 Закона Республики Татарстан от 16 января 2003 года № 3-ЗРТ «О государственной гражданской службе Республики Татарстан» (в редакции настоящего Закона), части 8 статьи 28 Кодекса Республики Татарстан о муниципальной службе (в редакции настоящего Закона).

3. Кабинету Министров Республики Татарстан и иным государственным органам Республики Татарстан в трехмесячный срок привести свои нормативные правовые акты в соответствие с настоящим Законом.

**Статья 4**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
26 декабря 2016 года
№ 107-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” Татарстан Республикасы Законына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $13^{1}$ статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Дәүләт хезмәтендә булуның иң чик яше – 65 яшь. Дәүләт хезмәтендә булуның иң чик яшенә җиткән, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка ярдәм итү өчен гамәлгә куелган “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категориясендәге дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәренә дәүләт хезмәте чоры әлеге дәүләт хезмәткәренең ризалыгы белән яллаучы вәкиленең карары буенча күрсәтелгән затның вәкаләтләр чоры тәмамланганчыга кадәр озайтылырга мөмкин.”;

2) 45 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктында “дәүләт хезмәтендә кимендә 15 ел стажы булса” сүзләрен “тиешле еллар эшләгән өчен пенсияне тиешле елда билгеләү өчен кирәкле дәвамлылыгы әлеге Законга кушымта нигезендә билгеләнә торган дәүләт хезмәте стажы булса” сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә “Дәүләт хезмәте стажы 15 ел булганда” сүзләрен “Тиешле еллар эшләгән өчен пенсияне тиешле елда билгеләү өчен кирәкле дәвамлылыгы әлеге Законга кушымта нигезендә билгеләнә торган дәүләт хезмәте стажы булганда” сүзләренә алмаштырырга, “15 елдан” сүзләрен “күрсәтелгәннән” сүзенә алмаштырырга;

в) 6 өлешнең беренче абзацына “класслы чин өчен оклад,” сүзләреннән соң “айлык вазыйфаи окладтан артыграк булмаган күләмдә айлык акчалата бүләкләү,” сүзләрен өстәргә;

3) түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

“Татарстан Республикасы
дәүләт граждан хезмәте турында”
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен дәүләт граждан хезмәте стажы**

| Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү елы | Тиешле еллар эшләгән өчен пенсияне тиешле елда билгеләү өчен кирәкле стаж |
|---|---|
| 2017 | 15 ел 6 ай |
| 2018 | 16 ел |
| 2019 | 16 ел 6 ай |
| 2020 | 17 ел |
| 2021 | 17 ел 6 ай |
| 2022 | 18 ел |
| 2023 | 18 ел 6 ай |
| 2024 | 19 ел |
| 2025 | 19 ел 6 ай |
| 2026 һәм киләсе еллар | 20 ел”. |

**2 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 28 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктында “кимендә 15 ел” сүзләрен “тиешле еллар эшләгән өчен пенсияне тиешле елда билгеләү өчен кирәкле дәвамлылыгы әлеге Кодекска 5 нче кушымта нигезендә билгеләнә торган” сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә “Муниципаль хезмәт стажы 15 ел булганда” сүзләрен “Тиешле еллар эшләгән өчен пенсияне тиешле елда билгеләү өчен кирәкле дәвамлылыгы әлеге Кодекска 5 нче кушымта нигезендә билгеләнә торган муниципаль хезмәт стажы булганда” сүзләренә алмаштырырга, “15 елдан” сүзләрен “күрсәтелгәннән” сүзенә алмаштырырга;

в) 8 өлештә “вазыйфаи оклад,” сүзләреннән соң “айлык вазыйфаи окладтан артыграк булмаган күләмдә айлык акчалата бүләкләү,” сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле 5 нче кушымта өстәргә:

“Муниципаль хезмәт турында
Татарстан Республикасы Кодексына
5 нче кушымта

**Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажы**

| Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү елы | Тиешле еллар эшләгән өчен пенсияне тиешле елда билгеләү өчен кирәкле стаж |
|---|---|
| 2017 | 15 ел 6 ай |
| 2018 | 16 ел |
| 2019 | 16 ел 6 ай |
| 2020 | 17 ел |
| 2021 | 17 ел 6 ай |
| 2022 | 18 ел |
| 2023 | 18 ел 6 ай |
| 2024 | 19 ел |
| 2025 | 19 ел 6 ай |
| 2026 һәм киләсе еллар | 20 ел”. |

**3 статья**

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт узган, “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45, 46 статьялары, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 статьясы нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукына ия булган һәм 2017 елның 1 гыйнварына кадәр хезмәттән азат ителгән затларга, 2017 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәвам итүче һәм 2017 елның 1 гыйнварына озак еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен кимендә 20 ел дәүләт граждан хезмәте стажы, муниципаль хезмәт стажы булган затларга, 2017 елның 1 гыйнварына Татарстан

Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәвам итүче, шушы көнгә кимендә 15 ел әлеге стажы булган һәм 2017 елның 1 гыйнварына кадәр "Иминият пенсияләре турында" 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясе алу хокукына ия булган затларга "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45, 46 статьялары, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 статьясы нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу хокукы, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45 статьясындагы 1 һәм 4 өлешләренә, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 статьясындагы 1 һәм 4 өлешләренә әлеге Закон белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алмыйча, сакланып кала.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия әлеге Закон үз көченә кергәнче билгеләнгән затларга тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләме 2017 елның 1 гыйнварыннан, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 45 статьясындагы 6 өлеше нигезләмәләрен (әлеге Закон редакциясендә), Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 28 статьясындагы 8 өлеше нигезләмәләрен (әлеге Закон редакциясендә) кулланып, яңадан саналырга тиеш.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары үз норматив хокукый актларын өч ай эчендә әлеге Законга туры китерергә тиеш.

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 ел, 26 декабрь
№ 107-ТРЗ